ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**6 декабрь 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 337**

## Биектау муниципаль районы бюжетыннан авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы бюжетыннан авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге Карарның нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанслар һәм икътисади сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы — Р.Г. Кәлимуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
06.12.2019 № 337

Биектау муниципаль районы бюжетыннан авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюжетыннан Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлек бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан субвенцияләр тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме “Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында”, 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү Биектау муниципаль районы Советының билгеле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр билгеле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Граждан хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны тормышка ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү һәм хезмәт өчен түләү хисаплау;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;

транспорт хезмәтләре;

коммуналь хезмәтләр;

милекне файдалану буенча хезмәтләр;

милекне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;

башка эшләр, хезмәтләр;

төп чаралар сатып алу;

матди запаслар сатып алу;

салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү;

башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) җирлек бюджетлары үтәлешенә хезмәт күрсәтү өчен ачылган шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килештерү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең Башкарма комитетына тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына субвенцияләрнең кулланылмый калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.